КАБИНЕТ МИНИСТРОВ
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2023 ел, 20 март г.Казань № 280

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Устав капиталын арттыру өчен Татарстан Республикасы дәүләт унитар предприятиесенә Татарстан Республикасы бюджетыннан субсидия бирү тәртибен раслау турында» 2021 ел, 11 сентябрь, 862 нче карары белән расланган Устав капиталын арттыру өчен Татарстан Республикасы дәүләт унитар предприятиесенә Татарстан Республикасы бюджетыннан субсидия бирү тәртибенә үзгәрешләр кертү хакында

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Устав фондын арттыру өчен Татарстан Республикасы дәүләт унитар предприятиесенә Татарстан Республикасы бюджетыннан субсидия бирү тәртибен раслау турында» 2021 ел, 11 сентябрь, 862 нче карары (Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2022 ел, 30 март, 291 нче, 2022 ел, 14 сентябрь, 1000 нче, 2022 ел, 16 декабрь, 1358 нче карарлары белән кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып) белән расланган Устав фондын арттыру өчен Татарстан Республикасы дәүләт унитар предприятиесенә Татарстан Республикасы бюджетыннан субсидия бирү тәртибенә түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

2.3 пунктның алтынчы абзацын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«чит ил, шул исәптән теркәлү урыны Россия Федерациясе Финанс министрлыгы тарафыннан раслана торган, Россия Федерациясендә активларга арадаш (офшор) ия булу өчен файдаланыла торган дәүләтләр һәм территорияләр (алга таба – офшор компанияләре) исемлегенә кертелгән дәүләт яки территория булган юридик зат, шулай ук устав (җыелма) капиталында офшор компанияләренең турыдан-туры яки турыдан-туры булмаган (өченче затлар аша) катнашу өлеше барысы бергә 25 проценттан арткан Россия юридик заты (әгәр Россия Федерациясе законында башкасы каралмаса) булып тормый. Офшор компанияләренең Россия юридик затлары капиталында катнашу өлешен исәпләп чыгарганда акцияләре Россия Федерациясендәге оештырылган торгларда әйләнештә йөри торган гавами (шул исәптән халыкара компания статусы булган) акционерлык җәмгыятьләре капиталында офшор компанияләренең турыдан-туры һәм (яки) турыдан-туры булмаган катнашуы, шулай ук мондый офшор компанияләренең башка Россия юридик затлары капиталында әлеге гавами акционерлык җәмгыятьләре капиталында катнашып тормышка ашырылган турыдан-туры булмаган катнашуы исәпкә алынмый;»;

әлеге Тәртипкә теркәлгән кушымтаның 1 пунктындагы алтынчы абзацын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«чит ил, шул исәптән теркәлү урыны Россия Федерациясе Финанс министрлыгы тарафыннан раслана торган, Россия Федерациясендә активларга арадаш (офшор) ия булу өчен файдаланыла торган дәүләтләр һәм территорияләр (алга таба – офшор компанияләре) исемлегенә кертелгән дәүләт яки территория булган юридик зат, шулай ук устав (җыелма) капиталында офшор компанияләренең турыдан-туры яки турыдан-туры булмаган (өченче затлар аша) катнашу өлеше барысы бергә 25 проценттан арткан Россия юридик заты (әгәр Россия Федерациясе законында башкасы каралмаса) булып тормый. Офшор компанияләренең Россия юридик затлары капиталында катнашу өлешен исәпләп чыгарганда акцияләре Россия Федерациясендәге оештырылган торгларда әйләнештә йөри торган гавами (шул исәптән халыкара компания статусы булган) акционерлык җәмгыятьләре капиталында офшор компанияләренең турыдан-туры һәм (яки) турыдан-туры булмаган катнашуы, шулай ук мондый офшор компанияләренең башка Россия юридик затлары капиталында әлеге гавами акционерлык җәмгыятьләре капиталында катнашып тормышка ашырылган турыдан-туры булмаган катнашуы исәпкә алынмый;».

Татарстан Республикасы
Премьер-министры А.В.Песошин